**ГЛАВА НИЖНЕТИМЕРЛЕКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422670, Республика Татарстан, Рыбно-Слободский район, ул.Советская., дом 72А, с.Верхний Тимерлек

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТҮБӘН ТЕГЕРМӘНЛЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
422670,Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Совет урамы, 72А йорты, Югары Тегермәнлек авылы

**Тел.: (8-4361) 28001 , факс: (8-4361) 28001 , эл.адрес: Ntim.Rs@tatar.ru**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

14 ноябрь 2023ел Югары Тегермәнлек авылы № 2

Гражданнарның үзара салымын кертү

һәм куллану мәсьәләсе буенча

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе

муниципаль районының Түбән Тегермәнлек

авылы торак пунктында гражданнар

җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 28.07.2004 № 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР ИТТЕ:

1.2023 елның 28 ноябрендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлегенең Түбән Тегермәнлек авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 13 сәгать 00 минутка билгеләргә, җыенны үткәрү урыны - Түбән Тегермәнлек авылының Мәдәният йорты.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2024 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тимерлек авыл җирлегенең Түбән Тегермәнлек авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, мобилизацияләнгән гражданнар гаиләсе, 1 төркем инвалидлардан тыш, 400 сум күләмендә үзара салым

кертүгә ризамы һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

- Энгельс,Тукая урамнары буенча юлларны ремонтлау өчен вак таш сатып алу;

- суүткәргечне ремонтлау һәм су белән тәэмин итү системаларын Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге милкенә рәсмиләштерү;

- яңа лампалар сатып алу, янган урам яктырткычларын алыштыру һәм аларга хезмәт күрсәтү;

- Түбән Тегермәнлек авылы җирлегендә урнашкан Түбән Тегермәнлек авылы юлларны тәртиптә тотуга;

“ЯКЛЫЙМ” “КАРШЫ”

3.Әлеге карарны дәүләт теркәвеннән соң Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлегенең түбәндәге адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштырырга: Түбән Тегермәнлек авылы, Мәктәп урамы, 7б йорты һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүматтелекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда.

4. Карар басылып чыккан (халыкка белдерелгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы

Балык Бистәсе муниципаль районы

ТубэнТегермэнлек

авыл җирлеге башлыгы вазыйфаларын

вакытлыча башкаручы А.С.Гарипов